Россия Федерациясе
мөселманнары Диния нәзарәте

بسم الله الرحمن الرحيم

# ГЫЙД ӘЛ-ФИТР — УРАЗА БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ, МӨФТИ ШӘЕХ РАВИЛ ГАЙНЕТДИН

# МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘСЕ

**Мәскәү**
Һиҗри 1444 елның 1 нче шәүвәле
Милади 2023 елның 21 нче апреле

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

**Бисмилләһиррахмәниррахим!**

**Мәрхәмәтлеләрнең мәрхәмәтлесе булган Аллаһ исеме белән!**

Рәхмәте киң булган галәмнәрнең Хуҗасы, күк белән җирне бар кылучы, бар мәхлүкат тарафыннан данлanучы һәм һәрнәрсәгә рәхимле Аллаһка мактау булсын! Пәйгамбәрләрнең һәм Расүлләрнең соңгысы Мөхәммәт галәйһиссәламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

**Кадерле дин кардәшләрем!**

**Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһ!**

**Сезгә Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәтен һәм бәрәкәтен сорыйм!**

Бүген без рәхмәт һәм рухи нур белән тулы изге Рамазан аеның тәмамлануын билгеләп үтәбез. Бу ай безнең өчен көчебезне һәм чыдамлыгыбызны сынау гына түгел, безне бар кылган Раббыбыз белән аралашу вакыты да булды. Рух һәм тән ягыннан чистартынып, без бөек Гыйд әл-Фитр бәйрәмен каршылыйбыз. Бу көнне Аллаһы Тәгалә гыйбадәт кылуда тырышучыларны һәм бер-берсе белән игелектә ярышучыларны юмарт рәвештә бүләкли.

Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам болай дигән:

لِلصَّائمِ فَرحتانِ: فَرحةٌ عِندَ فِطرِهِ، وفَرحةٌ يَومَ القيامةِ

*«Ураза тотучыга ике шатлык: беренчесе — авыз ачканда, икенчесе — [Кыямәт көнендә] Раббысы каршына килгәч, тоткан уразасы өчен сөенеч».*

Ураза тотучы Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршында басуын һәм аңа игелекле гамәлләре дәфтәренең күрсәтелүен күз алдына китерсен. Анда кылган яхшылыгының кечкенәсе дә, зурысы да төшереп калдырылмас, ул

язуда ураза, намаз,
садәка һәм башка
гыйбадәтләре тау кадәрле
игелеккә тиң булачак. Һәм байлык
та, балалар да файда китерә алмас ул
Бөек көндә, Аллаһ хозурына йөрәге пакъ
килеш басканнарга гына игелекле гамәлләре
шәфәгатьче булыр.

Без намаз кылдык, Коръән укыдык, игелекле гамәлләр кылдык һәм эчтән дә, тыштан да яхшырак булырга тырыштык. Бу ай безгә Аллаһның рәхмәтенә һәм мәгъфирәтенә ирешергә ярдәм итте.

Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам болай дигән:

الصيام والقرآن يشفعان للعبد يوم القيامة، يقول الصيام: أي رب منعته الطعام والشهوات بالنهار فشفعني فيه، ويقول القرآن: منعته النوم بالليل فشفعني فيه فيشفعان

*«Кыямәт көнендә Ураза белән Коръән Аллаһның колларын яклаячак. Ураза: «Ий Раббым! Көннеңякты вакытында мин аны ризыктан һәм җенси якынлыктан мәхрүм иттем, миңа аңа шәфәгать кылырга рөхсәт ит»,— дип әйтер. Ә Коръән: «Ий Раббым! Мин аны төнге йокыларыннан аердым, миңа аңа шәфәгать кылырга рөхсәт ит»,— дип әйтер, һәм аларның шәфәгате кабул ителер».*

Аллаһы Тәгалә аларның шәфәгатен кабул итәчәк, аннары әл-Кәрим –бик юмарт Раббыбыз, Үз мәхлүкларын иң бөек рәхмәтләре — Җәһәннәм утыннан азат итеп, Җәннәт рәхәте белән бүләкләячәк. Болар барысы да Рамазан аенда кылынган игелекле гамәлләрнең әҗере булачак.

Ий ураза тотучы, бу синең бүләгең, бу синең нигъмәтләрең, бу синең тәкъдирең, син Раббыңның әмерләрен ишеттең һәм аларга буйсындың, син Аның Китабын укыдың һәм анда язылганны үтәдең, син Аның Расүлен таныдың һәм аңа иярдең, һәм син иң бөек әҗерләргә ия булдың, бу — әл-Вәһһәб — бар нәрсәне бирүче Раббыбыз вәгъдә иткән, тәкъва мөэминнәрнең йорты булган, Җәннәт, һәм Ул Үз вәгъдәсен үтәде:

وَالْمَلَائِكَةُ يَدْخُلُونَ عَلَيْهِم مِّن كُلِّ بَابٍ
سَلَامٌ عَلَيْكُم بِمَا صَبَرْتُمْ
فَنِعْمَ عُقْبَى الدَّارِ

***«Фәрештәләр
ул җәннәтнең һәр
ишегеннән керер.
Түземле булганыгыз өчен сезгә —
Аллаһның сәламе, — диярләр. Дөнья
йортының нинди яхшы нәтиҗәсе инде бу!»***
(«Әр-Рәгыд» сүрәсе, 23–24 аятьләр).

Рамазанда кылынган гыйбадәтнең кабул ителүенең иң зур билгеләре — чын күңелдән тәүбәгә килү һәм үткәндәге гөнаһларны калдыру, шулай ук киләчәктә дә Аллаһы Тәгаләгә буйсынып, яшәү.

Аллаһы Тәгалә әйткән:

وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَ الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ

***«Ий мөэминнәр! Аллаһка тәүбә итегез,
шаять, бәхеткә ирешерсез».***
(«Ән-Нур» сүрәсе, 31 аять)

**Кадерле дин кардәшләр!**

Бу айда без үзара хөрмәт белән ышанычны ныгыттык, һәм бу кыйммәтләрне гаиләбездә, җәмгыятебездә һәм илебездә тәрбияләдек. Гыйд әл-Фитр — шатлык, үзара кайгыртучанлык һәм бердәмлек вакыты килде.

Бу бәйрәм көнендә Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә яшәүче бар мөселманны Рамазан аеның тәмамлануы белән котлыйм. Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны һәм кылган игелекле гамәлләребезне кабул итсен, йөрәкләребездәге иманны ныгытсын! Иманыбыз юаныч булып кына калмасын, ә игелекле гамәлләр белән хәйриячелекне дәвам итәргә көч бирсен. Аллаһ безгә Рамазан ае рухын ел дәвамында сакларга, җәмгыятебезне тагын да гаделрәк, шәфкатьлерәк һәм иминрәк итәргә ярдәмен бирсен. Аллаһы Раббыбыз һәрберебезне һәм илебезне һәртөрле бәладән сакласын! Мин Россия халыкларына тыныч күк йөзе һәм уңышка ирешүләрен телим, тынычлык һәм татулыкта, галәмнәрнең Хуҗасына гыйбадәттә һәм мәрхәмәт, гаделлек хакына кешелеккә хезмәт итеп яшәргә чакырам.

***Бәйрәм мөбарәк булсын, кадерле дин кардәшләр!***

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин***
*Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе*